| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 18.02.2021 | Казан шәһәре | № 27/2021 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 7 апре-лендәге 76 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 7 апрелендәге 76 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.10.2017 №283, 21.06.2018 №184 боерыклары ниге-зендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның беренче абзацында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның беренче абзацында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән дә (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәдән)), Татарстан Республикасы Тарифлар буенча

дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты рәисенең рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган, кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәтенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.»;

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Дәүләт комитеты тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

Конкурсны үткәрү, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры оештыру һәм тәэмин итү Дәүләт комитетының финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.4 пунктның алтынчы-җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квали-фикациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;»;

4.4 пунктта:

4.4.1 пунктчаның беренче абзацында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.2 пунктчада «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.5 пунктчаның икенче абзацында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.7 пунктчада «бәяли» сүзеннән алда «һөнәри дәрәҗәсен» сүзләрен өстәргә;

4.4.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.8. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең билгеле бер вакант

вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына
кертүгә) конкурс уздыру турында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

Конкурс комиссиясе беркетмәсе : _______

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге биләнә торган вакантлы вазыйфага конкурс нигезендә сайлап алу буенча тавыш бирү уздырылды:

_______________________________________________
(биләнә торган вакантлы вазыйфа атамасы)

____________________________________________________________
(структур бүлекчә аталышы)

Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1. _______________________«хуплый» ____ «каршы» _____«тавыш бирмәде»____
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2. ________________________«хуплый» ____ «каршы» _____«тавыш бирмәде»____
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

3. ___________________________«хуплый» _____ «каршы» ___«тавыш бирмәде»__
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча___________________________________________________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

конкурс комиссиясе әгъзаларыннан иң күп санлы тавыш алды, ул тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары исәбенең ____ процентын тәшкил итә.

Конкурс комиссиясе рәисе ___________________________________________
(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары ________________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе секретаре ______________________________________________

(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе әгъзалары ___________________________________________________

(имза) (тулы имза)

________________________________________________________________________________

(имза) (тулы имза)

Конкурсны үткәрү датасы «__» ____________ 20__ ел.».

2. Дәүләт комитетының конкурс комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклый дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В.Павлов